РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

12.04.2019 ел №213

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларына һәм законнарына үзгәрешләр кертү буенча мониторинг үткәрү турында Нигезләмәне раслау хакында**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлеген камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән (бастырып чыгарылган) законга һәм муниципаль норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү мониторингы үткәрү буенча Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1.Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнарының законнар һәм муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү турындагы нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнары:

үз нормаларын иҗат итү эшчәнлегендә әлеге карарның 1 пункты белән расланган Нигезләмәгә таянып эш итәргә;

күрсәтелгән Нигезләмәнең үтәлеше өчен җаваплы затларны билгеләргә;

җаваплы затлар тарафыннан билгеләнгән муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи күрсәтмәләренә тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына муниципаль норматив хокукый актларның, законнарның, муниципаль берәмлекләр Уставларының туры килүен системалы тикшереп торуны гамәлгә ашыру максатларында мониторинг үткәрүне тәэмин итә торган муниципаль норматив хокукый актлар кабул итүне тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Чирмешән муниципаль районының Интернет челтәрендә рәсми сайтында бастырып чыгарырга

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башлыгы урынбасарына һәм Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән ун көн узгач үз көченә керә.

Башлык, муниципаль районы
Советының рәисе Ф.М. Дәүләтшин